| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 22.12.2022 | г. Казань | № Пр-1158/2022 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алуның кушымтада бирелгән тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2.Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 168 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә берүзе генә башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмалар идарәсендә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә

органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 29 апрелендәге 87 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә берүзе генә башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмалар идарәсендә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 8 сентябрендәге 498/2021 номерлы.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2022 елның
«__» ______ _________
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты) тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Рәис) аларга карата яллаучы вәкиле булып торган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән Дәүләт комитетының беренчел һөнәри берлек оешмасының сайлап алу органы белән идарә итүдә граждан хезмәткәрләренең башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу очракларына кагылмый.

3. Граждан хезмәткәренең коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималына китермәскә тиеш.

4. Коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашу өчен рөхсәт алу граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә язма рәвештә гариза тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Граждан хезмәткәре Дәүләт комитетының коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затына (алга таба – Җаваплы зат) коммерциясез оешма белән идарә итә башлаганчы гариза бирә.

6. Җаваплы зат гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

7. Теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә Җаваплы зат гаризаны карый һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

8. Гаризаны барышында Җаваплы зат гариза тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуының

планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итү яки рөхсәт бирмәү турында тәкъдим булырга тиеш.

8. Җаваплы зат, граждан хезмәткәренә коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен, бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, гаризаны рәискә тапшыра.

Рәис Җаваплы заттан гариза алган көннән ике эш көне эчендә карар кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюция теркәү юлы белән рәсмиләштерелә.

9. Җаваплы зат карар кабул ителгәннән соң ике эш көне дәвамында граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм рәис резолюциясе белән гаризаның күчермәсен аңа имзалатып тапшыра. Рәис резолюциясе куелган гаризаның төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисенә

________________________________________
________________________________________
(Ф.И.А., били торган вазыйфа һәм
________________________________________
структур бүлекчә,
________________________________________
яшәгән урын адресы, телефон номеры)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу турында гариза

Миңа ____________________________________________________________
(оештыру-хокукый формасы, исеме, ИНН, адрес)
белән түләүсез нигездә идарә итүдә______________________________________
________________________________________________________________________
(бердәнбер башкарма орган яки коллегиаль идарә органы исеме)
сыйфатында катнашуга рөхсәт бирүегез турында үтенәм.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ____________ | ________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу турында гаризаларны теркәү журналы

| т/с | Теркәү датасы | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Җаваплы зат имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |